| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
|---|---|---|
| Исполнительный комитет<br>Менделеевского<br>муниципального района | | Менделеевск муниципаль<br>районы<br>башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.09.2022 ел Менделеевск ш. №541

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 12 апрелендәге 265 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты территорияләрен тотрыклы үстерүне тәэмин итү зарурлыгы максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 12 апрелендәге 265 номерлы «Менделеевск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» карары белән расланган Менделеевск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 5 пунктны схемадан төшереп калдырырга

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Киоск<br>«Аяк киемен ремон | Пушкин урамы<br>(4 нче йорт янында) | Аяк киемнәрен рем<br>буенча хезмәтләр к | ел буе |

1.2 Схемага 46, 47 пунктын кертергә

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 46 | Павильон | "Ушковлар утравы"<br>парки | Иҗтимагый<br>туклану | ел буе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 47 | Киоск<br>«Аяк киемен ремон | Бурмистров ур.<br>(15 нче йорт янында) | Аяк киемнәрен рем<br>буенча хезмәтләр к | ел буе |

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында: www.mendelevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru. урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, алгарышлы социаль икътисадый үсеш территориясен һәм эшмәкәрлекне үстерү буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы С.В. Метальников

Килештерелде

Җитәкче урынбасары Л.Р. Әхмәтов

Хокук бүлеге башлыгы Е.С. Царева

Сатып алу һәм сәүдә бүлеге башлыгы урынбасары М.В. Бургонова